## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

## КАРАРЫ

2022 ел, 21 февраль № 92

**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советы депутаты статусы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы "Россия Федерациясе субъектларында җәмәгать хакимиятен оештыруның гомуми принциплары турында" гы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советы карар итте:

1. «Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советы депутаты статусы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 9 августындагы 61 номерлы Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советы депутаты статусы турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 статьяның 2 пунктындагы «б» пунктчасында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасының югары вазыйфаи заты» сүзләренә алмаштырырга;

11 статьяның 1 пунктында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасының иң югары вазыйфаи заты» сүзләренә алмаштырырга;

11 статьяның 2 пунктында «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасының югары вазыйфаи затына» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карар 2022 елның 1 июленнән үз көченә керә.

3.Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында әлеге карарны бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).

4.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Апас муниципаль районы башлыгы урынбасары Л.Т.Хантимеровка йөкләргә.

**Татарстан Республикасы**
**Апас муниципаль районы Башлыгы**
**Татарстан Республикасы Апас муниципаль**
**районы Советы рәисе** **А.Г. Җиһаншин**